УДК 908 DOI: 10.22378/he.2019-4-1.99-108

# АВЫЛ ТАРИХЛАРЫН ӨЙРӘНҮДӘ ТАРИХИ ЧЫГАНАК БУЛАРАК МЕТРИКА КЕНӘГӘЛӘРЕ

# [МЕТРИЧЕСКИЕ КНИГИ КАК ИСТОЧНИК ПО ИСТОРИИ НАСЕЛЕННЫХ ПУНКТОВ]

***Э.К. Салахова***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*ilsalah@mail.ru*

В последние десятилетия изучение истории населенных пунктов приобрело большую популярность. К этой теме обращаются не только профессиональные историки, но и любители истории. Последние при сборе материала и написания очерков по истории деревень сталкиваются с трудностями в определении источников и неразработанностью методологии изучения истории отдельных регионов. Цель публикации – анализ возможностей метрических книг в качестве источника в изучении истории населенных пунктов. В статье раскрываются некоторые исследовательские трудности работы с ними. Автор определяет источниковедческие возможности метрических книг при изучении истории населенных пунктов, показывает особенности содержавшейся в них информации в контексте отдельных регионов, указывает на проблемы, открывающие данный источник для исследователей микроистории.

**Ключевые слова:** история населенных пунктов, метрические книги, татары, краеведение, деревня, исторический источник.

**Для цитирования:** Салахова Э.К. Авыл тарихларын өйрәнүдә тарихи чыганак буларак метрика кенәгәләре // Историческая этнология. 2019. Т. 4, № 1. С. 99–108. DOI: 10.22378/he.2019-4-1.99-108

Авыл тарихларын булдыру, аларны өйрәнү – шактый катлаулы фәнни тема. Авылларның, торак пунктларының тарихи картинасын бары тик киңкырлы чыганак базасында гына күзаллау мөмкин.

Үткәнне чагылдыручы мөһим чыганакларларның берсе – һичшиксез, мәхәллә метрика язмалары. Алар авыл тарихын, ыру тарихын өйрәнү өчен мөһим документлар, әмма шактый соңлап фәнни әйләнешкә кергән тарихи чыганаклар. Метрика язмалары – гражданлык халәтен теркәгән документлар.

Православия метрика язмалары 3 сәхифәдән торса, мөселман метрика язмалары 4 сәхифәне үз өченә ала. Мөселман метрика язмаларында кеше тормышында булган төп этаплар: туу, никах, талак һәм вафат булу фактлары теркәлә. Православия метрика кенәгәләренең аерылышуны теркәү сәхифәсе юк.

Билгеле булганча, православиядәге халыкны метрика кенәгәләренә терки башлау 1722 елда гамәлгә куела, ә Мәскәү өчен туу һәм вафат булуны теркәү 1702 елда ук башланган була. Католиклар өчен бу 1826 елда, ә мөселманнар өчен 1828 елда гамәлгә керә, лютеран чиркәве өчен бераз соңрак – 1832 ел, яһүдиләр өчен – 1835 ел, раскольникларда – 1874 ел.

Сенат 1828 елның 21 сентябрендә кабул иткән «О введении в употребление метрических книг по Оренбургскому духовному магометанскому управлению» указы Оренбург Диния нәзарәтенә һәм Таврия мөфтиятенә караган барлык губерналар өчен тарала. Шушы указ нигезендә һәр мәхәллә ике экземплярда метрика кенәгәсен ала [2]. Тутырылган метрика кенәгәсенең төп нөсхәсе киләсе елның февраленнән дә калмыйча нәзарәткә җибәрелә, ә копия исә мәхәлләнең үзендә кала.

Башлангыч этапта метрика алу, аны җибәрү, алып бару чыгымнары 700 сум күләмендә дәүләт казнасыннан капланган булса, алга таба бу тулысы белән мәхәллә өстенә йөкләнә.

Метрика язмалары нигезендә дәүләт органнарына кирәкле булган белешмә кәгазьләре, метрика язмаларыннан күчермәләр бирелгән. Шулай итеп, Диния нәзарәте үзенә күрә бер нотариаль контора статусын да ала. Метрика язмалары нигезендә мирас белән бәйле сораулар чишелгән, туганлык мөнәсәбәтләре расланган, кешенең яше билгеләнгән, солдатка алынганда метрика язмасыннан күчермә-белешмә бирелгән. Үз мәхәлләсенән читтә, башка мәхәлләдә никах укылганда да кызның яшен белү өчен метрикадан белешмә таләп ителгән. Бу – яше җитмәгән кызларның никахка керү очрагын булдырмас өчен шулай эшләнгән. Метрика кенәгәсен имамга җиткерү, тутырылганын кире нәзарәткә кайтару процессы беренче чорда озак вакыт ала: алар шәһәр, авыл полиция участоклары, губерна идарәсе аша узган. 1856 елның июлендә бу процесс күпмедер гадиләштерелә: губерна идарәсенә керми генә, турыдан-туры полиция участокларына тапшырыла башлый [8, б.81–96].

1918 елда, Гражданлык халәте хакындагы декрет чykканнан соң, метрика алып бару руханилар вәкаләтеннән алына, вазыйфа дәүләткә күчә һәм ул оешма ЗАГС дип атала башлый. Әмма шулай булса да, бу вакыттагы сәяси халәт, гражданнар сугышы әлеге декретның чын мәгънәсендә гамәлгә керүен тоткарлый. Кайбер мәхәллә имамнары, традицияне дәвам итеп, 1930 елларга кадәр метрика кенәгәләрен тутыру эшен алып баралар. Бу чор метрика язмалары, юридик көчкә ия булмаса да, тарихи чыганак буларак гаять мөһим. Болганчык чорның сакланып калган документлары күп түгел; муллалар тарафыннан алып барылган метрика язмалары бу чорны күзаллауда, рәсми булмаса да, тарих өчен кыйммәтле.

Хәзерге вакытта Россия архивларында 1829 елдан башлап XX гасырның 20–30 елларына кадәр вакытны иңләгән метрика кенәгәләре бар. Метрика кенәгәләре саклана торган фондларның тулылыгы төрле архивларда төрлечә, әлбәттә. Күп кенә торак пунктларының метрика кенәләре вакыт ягыннан 1918 ел белән чикләнә. Югарыда әйтелгәнчә, бу 1918 елгы декрет белән бәйле.

Мөселман метрика язмаларының иң зур коллекциясе Башкортостан Республикасының Милли архивында саклана, чөнки бу архив Диния нәзарәтендә озак еллар буе тупланып барган документларны саклый [1, б.54–59]. Диния нәзарәтенә һәр ел саен барлык мәхәллә метрика кенәләренең төп нөсхәләре җибәрелгән. Төбәкләрдә, губерна башкаласы булган шәһәрләрдә, нигездә, икенче экземплярлар, әмма кайбер авылларның беренче экземпляр метрика кенәгәләре дә саклана. Башкортостан Республикасының Милли архив фондындагы метрика язмаларының уникальлеге шунда: монда Сенат указыннан соң ук тутырылган кенәгәләр саклана, ә региональ архивларда, шул исәптән Татарстан Дәүләт Архивында да, нигездә, метрикалар 1860 еллардан башлап кына тупланган. Бары тик аерым авылларның гына элегрәк чор метрикалары бар. Татарстан архивында татар телендәге иң «карт» метрика язмасы 1829 елга карый.

Хәзерге вакытта республика архивында татар телендә гарәп язуы белән язылган 4022 берәмлек документ саклана [4, б.39–41]. Монда, нигездә, мәхәллә метрикалары 1860 еллардан гына башлана. Моннан кала, татар-мөселман мәхәлләләре булган барлык төбәк архивларында да татар телле метрика язмалары бар. Россиянең башка төбәкләрендәге метрика документларының сакланышы, тулылыгы ягыннан Әстерхан архивын аерым билгеләп үтәргә кирәк [5, б.86].

Метрика язмалары, бер караганда, барлык төбәкнеке дә бертөрле, алар стандарт, барысы да кабул ителгән бер формада эшләнгән [3]. Анда бары тик туу, никах, талак һәм вафат фактлары теркәлгән. Алар үзенә күрә бер исемлек формасындагы документлар. Шуңа күрә дә метрика язмалары нәсел тарихын өйрәнүчеләр, шәҗәрә төзүчеләр тарафыннан яратып кулланыла.

Метрика язмалары шәҗәрә төзү өчен төп чыганакларның берсе, әмма бердән-бер түгел. Метрика бары тик XIX йөзнең 30 елларыннан XX йөзнең 20 елларына кадәр булган ара хакында гына мәгълүмат бирә. Бу документлар аша ике-өч буын тормышын ачыклау мөмкинлеге бар, әмма алар, элегрәк чор документларына барып тоташып, шул вакытларда яшәгән бабайларны ачыклауга күпер булып та тора.

Метрика язмалары үткән гасырның 90 еллар ахырыннан төбәкне өйрәнүчеләр тарафыннан кулланыла башлады, соңгы 10–20 ел эчендә бу документларга мөрәҗәгать итү бермә-бер артты. Әйтергә кирәк, бу документларга кызыксынучылар тарафыннан зур ихтыяҗ Башкортостан, Татарстан архивларында күзәтелә.

Хәзерге вакытта метрика язмалары чыганак буларак өйрәнелүдән бигрәк, аерым фактларны бирүче бер чыганак буларак кабул ителә. Күп очракта, метрика кенәгәләреннән бары тик исемнәр «чүпләү»гә генә кайтып калу шул дәрәҗәдәге бай тарихи чыганакны «йолку» кебек кенә күзалдына килә. Метрика язмалары, фәнни дәрәҗәдә комплекслы өйрәнгәндә, авыл, җәмгыять тарихын, аның яшәү рәвешен, сөйләш үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә торган уникаль чыганак. Ул бирә ала торган мәгълүмат башка язма чыганакларда, бигрәк тә рәсми документларда, була алмый. Шул ук вакытта метрика язмаларында төбәк тарихын, авыл тарихын язу өчен әзер сюжет юк, берничә еллык метрика язмаларын өйрәнеп кенә авыл тарихына бәйле фикерләр әйтү дә мөмкин түгел, авылның үзенчәлеген, яшәү закончалыгын, аның тормышындагы вакыйгаларны, аерым хәлләрне күрсәтү өчен тарихчы-тикшеренүче авылның 80–90 еллык метрика кенәгәләрен өйрәнеп чыгып кына фикер әйтергә, нәтиҗәләр ясарга мөмкин. XIX–XX йөзләрдә татар авыллары берничә мәхәлләдән, гадәттә ике, хәтта 4–5 мәхәлләдән торганлыгын исәпкә алганда, бу сан бермә-бер арта, чыганаклар базасы нык киңәя. Бары тик барлык метрика язмаларын комплекслы, һәр хәрефен өйрәнгәннән соң, аңа анализ ясаганнан соң гына фикер әйтергә мөмкин. Бары шул вакытта гына матур нәтиҗә булып авылның билгеле бер тарих аралыгындагы тормышы күзалдына килеп баса.

Әлбәттә бу – күп вакытны сорый торган, күп көч ала торган хезмәт, әмма нәтиҗәсе авыл тарихлары өчен алыштыргысыз материал. Мондый тәҗрибә Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән Иске Җөри авылы тарихын яктырткан китап кысаларында башкарылды. Иске Җөри авылының метрикаларын өйрәнеп, бу авылның шул чордагы картинасы әлеге документлар нигезендә мөмкин кадәр торгызылды.

Метрика язмалары аша авыл тарихларын өйрәнүнең берничә юнәлеше бар. Беренчедәнметрика кенәгәләре демография мәсьәләсен өйрәнү, аның динамикасын, үзгәрешен күрсәтү өчен менә дигән чыганак. Туу һәм вафат булу сәхифәләре шул чорның гомер озынлыгын яктыртучы иң объектив документ. Вафат сәбәпләренә карап, шул чорда кеше гомерен өзгән авыруларны күрсәтү, йогышлы авыруларның эпидемия дәрәҗәсенә җиткән елларын ачыклау мөмкинлеге бар. Тирәнтен тикшергәндә, бер нәсел кешеләренең вафат булу сәбәпләрен ачыклап, нәселән килә торган авырулар, нәселнең «йомшак» ягын, нинди авыруга ешрак бирешкәнлеген дә күзәтергә мөмкин [7, б.294–299].

Метрика кенәгәләренең тагын бер үзенчәлекле һәм көчле чыганакчыл мөмкинлеге – ул билгеле бер авылның аралашу, никахлашу географиясен ачыклау. Метрика кенәләрен бу юнәлештә өйрәнү Ашыт җыены авыллары тарихын язганда кулланылды, метрика язмаларында теркәлгән никах фактларына таянып, авылларның никахлашу географиясе ачыкланды, шул мәгълүматлар картага төшерелде. Бу да әлегә кадәр булмаган, беренче

эшләнгән башлангыч бер тәҗрибә булды. Бу эш зур хезмәт таләп итә, нәтиҗә ясаганчы күпсанлы документларны карап чыгып анализларга кирәк. Бер-ике кешесе генә никахлашкан авылларны аралашкан, кыз алышкан авыллар рәтенә кертә алмыйбыз, моның өчен бары тик никах җепләре гасыр дәвамында булган, ул авыллар белән кыз алышу-бирешү даими барган авылларны күзәтү кирәк.

Метрикалар бирә ала торган информациянең тагын бер кызыклы ягы – ул никах вакытында бирелгән мәһәр күләме. Никах сәхифәсенә язылган суммаларны бербөтен итеп карап анализлаганда, авыл кешесенең матери-аль мөмкинлеген, моннан кала, аерым бай нәселләрне ачыкларга да мөмкин. Мәһәр күләменең кайбер вакыт аралыгында кимүе – илдәге эко-номик халәтнең, авыл кешесенең хәлен күрсәтә торган фактор.

Мәхәллә метрикаларында теркәлгән талак саны да җәмгыятьнең көзгесе. Татар авылларында талак никах белән чагыштырганда бик аз. Кайбер елларда, дистәләгән никах булып та, талак булмаска мөмкин, шәһәрдә картина башкачарак булуы ихтимал. Талакның булу-булмавы, аның ешлыгы төрле факторларга бәйле. Шул факторларның берсен генә әйтеп үтәсе килә. Талак җәмгыятнең халәтен, аның тотрыклылылыгын күрсәтә торган фактор. Экономик һәм дә сәяси хәл тыныч булганда, талак саны азрак була. 1917 елга таба талак саны арта башлый, бу – турыдан-туры җәмгыятьтәге вакыйгалар белән бәйле, сугыш елларында да талак саны арта.

Метрика язмаларындагы исемнәргә анализ ясау да кызыклы нәти-җәләр бирә. Һәр төбәк метрика язмаларында үз төбәгенең үзенчәлеге ча-гыла. Казан татарларында шул чорда бары тик ислам белән бәйле исемнәр генә кулланылса, Минзәлә өязенең Рангазар авылында XIX гасыр ахырына кадәр балалрга төрки исемнәр дә кушылуы кызыклы факт. Мисал өчен, Асылкош, Бәхетгәрәй, Гөлҗимеш, Гөлстан һ.б. шундый исемнәр.

Әстерхан татарларындагы исемнәр дә шактый кызыклы картина ача. Аларда, Казан татарларыннан аермалы буларак, Хаҗи-, Ак- алкушымчасы булган исемнәр бик күп кулланылган. Мисал өчен, Хаҗисолтан, Хаҗи-нияз, Хаҗибибә һ.б. Әстерхан ханлыгының Хаҗитархан дип аталуы белән халкы исемнәренә шундый алкушымча кушуда бәйләнеш бар, әлбәттә. Ак-алкушымчасы белән Акбибә, Акбаба, Акгөлсем һ.б. исемнәре бары тик ул як татарларында гына очрый. Баба – ата мәгънәсен белдерүче сүз, бу угыз компонеты. Хан-компонеты булган хатын-кыз исемнәре, әстерхан татар-ларыннан кала, башка якта бик сирәк очрый. Шундыйлардан, Әминәхан, Бибихан һ.б. Әстерханның җирле халыкларында, йорт нугайларында очра-ган исемнәр Кавказ халыклары исемнәренә охшаганлыгы белән кызыклы. Мисал өчен, Сухтали, Мәүлетгали, Утагали. Сухтагали. Кеше исемнәрен өйрәнү генә дә әстерхан татарларының (нугайларның) тарихның бер эта-бында Кавказ җире белән бәйләнешен күрсәтә. Кеше исемнәрендә утрак тормышка кадәр булган күчмә чорның аерым чаткылары саклану – тарихи яктан кызыклы бер күренеш. Мисал өчен, Сәетләр авылында Мамбат,

Нурмамбат, Саидмамбат исемнәрендә Мөхәммәд дигән сүзнең Кавказ халыкларындагыча Мамбат рәвешендә генә әйтелүе күренә [5, б. 86–95].

Исемнәр белән бәйле тагын бер мөһим моментка тукталасы килә. Шәҗәрәләр эшләгәндә игътибар ителергә тиешле факт: татарларда бер үк исем бер нәсел кешеләре арасында кабатланмаска тиеш була; бер үк төрле исем кабатлана икән, бу исем, шул исемдәге кеше вафат булганнан соң гына, икенчесенә кушыла. Татарларда кече яшьтә үлгән баланың исемен аңардан соң туганына кушу гадәте бар. Бер нәселдә исән булган кешенең исемен кушу очрагы булса да, бу бик сирәк күренеш, яисә бертөрле исемнең кабатлануы нәселнең ерак тармагында гына булырга мөмкин.

Метрика язмаларыннан шактый катлаулы проблема – социаль катламнарны өйрәнү, аларны күзәтү мөмкинлеге бар. Метрика язмаларына социаль катлауны язу таләп ителмәгән; Диния нәзарәте таләбендә бары тик мещан, дворян, почетный гражданин булган очракта гына катламны күрсәтү кирәк диелә. Шулай булуга карамастан, имамнар күп очракта барысының да социаль катламын язып барганар [3]. Зирагатьче, игенче, крестьян, солдат, мулла, мөәззин һ.б. Әмма ләкин бу тарих өчен, хәзерге тикшеренүчеләр өчен бик мөһим, авыл тарихларын, халык тарихын өйрәнгәндә бу мәгълүмат авыл халкының яшәү халәтен ачыклауга мөмкинлек бирә.

Моннан кала, Минзәлә, Бөгелмә өязләре документларында типтәр һәм башкорт дигән катлау бар. Метрикада яисә башка төр документларда күрсәтелгән башкорт катлавы еш кына халык исеме, милләт атамасы буларак аңлана. Шулай итеп, профессиональ тарихчы булмаган, татарларда социаль катлам тарихын, аның үзенчәлеген белмәгән кызыксынучылар ялгыш караш тудыралар.

Социаль катлам белән бәйле бик кызыклы бер фактны аерып атыйсы килә: Тәтеш өязенә кергән Яңа Чәчкап авылында XIX гасыр ахырында авыл кешеләренең социаль статусы буларак «падишаһ коллары» дип языла. Безнең фикеребезчә, мулла удел крестьяннарын (удельные крестьне) шулай итеп язган булырга тиеш. Шул ук өяздә Коллар авылы (хәзерге Апас районы Кызыл Тау авылы) дип аталган авыл бар, Казан артында да Коллар авылы билгеле. Нинди коллар турында сүз бара? Бу – авыл крестьяннарының статусы авылга исем дә булырга мөмкин. Монда өйрәнерлек, фикер әйтерлек нәрсәләр бар [6, б.300–307].

Шәһәр метрика язмалары аша халыкның миграциясен, аның социаль составын билгеләү мөмкин. Мисал өчен, Казан, Әстерхан шәһәрләре метрикалары аша без шул чорда шәһәргә кайсы авыллардан күчеп килгәннәрне күзәтә алабыз. Әҗем мәчете мәхәлләсендә заводта эшләүче кешеләр теркәлгән; метрика язмалары заводка эшкә килеп, Казанда төпләнеп калганнарның чыгышы белән кайсы авыллардан булуын күрсәтә.

Әстерхан метрика язмаларына аерым тукталасы килә: алар аша Әстерхан татарлары формалашуда катнашкан, шул төбәкләргә күчеп килгән башка губерна кешеләрен ачыклау мөмкинлеге бар. Бу төбәк

халкының формалашуында җирле халык белән Урта Идел һәм Урал татарлары катнашы күренә. Әстерхан шәһәре метрика кенәгәләре буенча шәһәрнең Татар бистәсе – Тияктә Казан губернасының Тәтеш өязе авыл кешеләре бик күп, шулай ук Спасс, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Чабаксар өязе авылларыннан чыккан кешеләр күренә. Тау ягы кешеләренең читкә китү юнәлеше итеп нәкъ менә Әстерхан ягын сайлану – Казан һәм Әстерхан ханлыгы чорыннан ук килгән тарихи бәйләнешнең чагылышы булу мөмкин. Әстерхан ягында Тәтеш өязеннән күчкән кешеләр нигезләгән авыл да булуы бу хакта сөйли. Моннан кала Әстерхан татарлары составында чыгышлары белән Пенза, Сары Тау, Нижгар, Самара кешеләре дә зур урын алып тора. Бу – шәһәр халкы картинасы. Әстерхан төбәге авыл тарихлары, метрика кенәләре материалларына караганда, бераз башкачарак [5, б.86–95].

Метрика язмалары торак пунктта булган гадәттән тыш хәлләрне дә чагылдыра. Авыл тарихына караган күп мәгълүматны рәсми документлар, дәүләт органнары тарафыннан тудырылган документлардан таба алмыйбыз, ә менә метрика язмаларыннан аларны алырга була. Мисал өчен, авылда янгында янып үлүчеләр, суга батучылар, яисә көнкүреш травмасы нәтиҗәсендә вафат булучылар һ.б булу турындагы фактлар авыл тормышындагы хәлләрне күрсәтә.

Татар авылларында үз-үзенә кул салу, кеше үтерү очраклары юк диярлек; булган очракта, бу – авылның рухи халәтен, кешеләренең әхлак дәрәҗәсен күрсәтә торган бер чаткы. Аракы эчеп үлү очраклары XIX йөз авыл метрика язмаларында күренми диярлек, ә XX йөздә шәһәр метрика язмаларында ул фактның да чагылуы – мөселман кешесенә хас булмаган нәрсәләренең дә татар җәмгыятенә керүен күрсәтүче аяныч бер күренешнең чагылышы. Никахсыз бала туу, әтисе билгесез дип күрсәтелүләр дә юк дәрәҗәсендә.

Метрика кенәгәләрендә тамга дигән билгеләр бар. Алар никах, талак сәхифәләрендә куела. Һәр нәселнең үз тамгасы булган; нәсел зурайгач, тармаклангач, тамга формасының төп нигезе шул калса да, нәселнең аерым тармагы, шул төп нигезгә бер элемент өстәп, үзенең тамгасын булдыра. Метрикаларда куелган тамга, татарларда XIX–XX йөз башында кулланылган тамга шул традициянең бер чагылышы гына. Язу культурасының тарихы бик борынгы булган, үз алфавиты булган халыкларда, бигрәк тә татарларда тамга төп роль уйнамый, ул кулланылуын традициягә бер ихтирам буларак кына дәвам иткән. Язу белгән кешеләр кул кую өчен бу вакытта тамга кулланмыйча, ә үз исемнәрен «фәлән фәлән углы» дип язып куйганнар. Татарларда тамга дигән нәрсә, башкортлар яисә башка төрки халыкларда булган кебек, зур әһәмияткә ия түгел. Метрика язмалары аша үз нәсел тамгаңны ачыклау кызык, әмма ләкин аңа тирән мәгънә салу кирәк түгел.

Югарыда сөйләнгән моментлар, метрика язмаларының авыллар, төбәк тарихын өйрәнүдә чыганак буларак, аларның чыганакчыл мөмкин-

лекләрен күрсәткәннәрнең кайберләре генә. Авыл тарихларын, халык тарихын өйрәнүдә бу чыганаклар төп урыннарның берсендә булырга тиеш, әлбәттә, һәм шул ук вакытта бу чыганаклар шактый катлаулы, эшләү өчен зур әзерлек таләп иткәнен дә онытмаска кирәк.

Авыл тарихларын язганда бу дәрәҗәдә анализ үткәрү, метрика язмаларыннан никадәр файдалану реаль булуы хакында сүз алып барганда түбәндәгеләрне кыенлыкларны әйтәсе килә. Беренчедән, метрика язмаларын бар яклап комплекслы өйрәнеп чыгу бик авыр, күп вакыт һәм зур хезмәт сорый. Әмма аерым аспектларны өйрәнү мөмкинлеге генә тудырылса да начар түгел. Аерым вакыт аралыгында авыл тормышын, халкының хәләтен күрсәтү мөмкинлеген дә булдырып була. Икенчедән, коммерция максатларында метрика язмаларына карата булган ажиотаж профессиональ тарихчылар өчен дә чикләүләргә китерде. Документлар зур тизлек белән туза башлау сәбәпле, бу документларны кулган бирү күп кенә архивларда чикләнде. Архив системасында барган цифлаштыру бу проблеманы чишәргә тиеш. Әмма, беренчедән, әле бу эш күптән түгел генә башланды, икенчедән эшләнгән кадәресе дә сыйфат ягыннан камил түгел. Мондый документларны карау кәгазь вариантын карау белән чагыштырганда вакыт ягыннан 2–3 тапкыр озаграк башкарыла. Шулай булуга да карамастан, булган кадәр мөмкинлектән файдаланып, профессиональ тарихчылар авыл тарихларын язганда бу төр чыганакларны кулланырга тырыша. Метрика кенәгәләре архив төшенчәсе буенча «кыйммәтле документлар» категориясенә керә, әмма алар «уникаль документлар» булырга тиешләр. Чөнки татар телендә язылган, татар теленең бар сөйләш төрләрен саклаган мондый документлар – Россия архив фондында бары тик метрика язмалары гына.

## СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ


1. Кутушев Р.Р. Мусульманские метрические книги в Центральном государственном архиве Республики Башкортостан // Отечественные архивы. 2012. № 4. С. 54–59.
2. О ведении метрик и официальных документов // Сведения Оренбургского духовного управления. 1916. № 20. С. 13–14.
3. О форме ведения метрик // Сведения Оренбургского Духовного управления. 1916. № 12–13.
4. Салахова Э.К. Коллекция магометанских метрических книг в Национальном архиве Республики Татарстан // Отечественные архивы. 2008. № 3. С. 39–41.
5. Салахова Э.К. Метрические книги как источник изучения татарской общины г. Астрахани (вторая половина XIX – начало XX в.) // Историческая этнология. 2016. Т. 1, № 1. С. 86–95.
6. Салахова Э.К. Метрические книги как источник по изучению социально-экономической жизни и демографической картины татарских деревень второй половины XIX века // Российская деревня: социально-экономическая история и современность: VI Всероссийская (XIV Межрегиональная) конференция истори-

ков-аграрников Среднего Поволжья. Ульяновск: Правительство Ульяновской области, Агентство передовых инициатив, технологий, проектов. Ульяновский государственный педагогический университет имени И.Н. Ульянова, 2016. С. 300–307.

7. Салахова Э.К. Метрические книги как источник знаний о татарском обществе XIX – начала XX века // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы изучения (к 80-летию профессора М.А. Усманова): сб. статей / сост. и науч. редакторы: Д.М. Усманова, Д.А. Мустафина, М. Кемпер. Казань: Казан. ун-т, 2015. С. 294–299.

8. Салахова Э.К. Мусульманские метрические книги России // Эхо веков=Гасырлар авазы. 2018. № 1. С. 81–96.

**Сведения об авторе:** Салахова Эльмира Кадимовна – кандидат исторических наук, старший научный сотрудник, отдел историко-культурного наследия народов РТ, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7А. Казань, Российская Федерация); ilsalah@mail.ru

## REGISTERS OF BIRTHS AS A SOURCE ON THE HISTORY OF SETTLEMENTS

***E.K. Salakhova***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*ilsalah@mail.ru*

The study of the history of human settlements in recent decades has become very popular. Not just professional historians, but also fans of history show interest in this problem. Some amateur historians face the issue of defining a range of sources and the development of a methodology for studying the history of individual regions in the process of collecting materials and writing essays on the history of villages. The purpose of this publication is to analyze the potential of metric books for solving the above-mentioned task. These documents contain the facts of birth, marriage, divorce and death. Registers of births are an invaluable source for restoration of pedigrees, histories of sorts. The article explores the methodological problems of working with these sources. The author defines the source-study potential of metric books for researching the history of settlements. In addition, the author shows the features of the information contained in the registers of births of different regions. The author points out the problems that reveal this source fo microhistory researchers.

**Keywords:** history of human settlements, register of births, history of Tatars, local history, village, historical source.

**For citation:** Salakhova E.K. Registers of births as a source on the history of settlements. *Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology*, 2019, vol. 4, no. 1, pp. 99–108. DOI: 10.22378/he.2019-4-1.99-108

## REFERENCES


1. Kutushev R.R. Musulmanskie metricheskie knigi v Tsentralnom hosudarstvennom archive Respubliki Bashkortostan [Muslim parish registers in the Central State Archive of the Republic of Bashkortostan]. *Otechestvennye archvy – Domestic Archives,* 2012, no 4, pp. 54–59. (In Russian)
2. O vedenii metric i ofitsalnykh dokumetov [On maintenance of metrics and official documents]. *Svedeniia Orenburhskoho Duchovnoho upravleniia* [The data of the Religious Administration of Orenburg], 1916, no 20. (In Tatar)
3. O forme vedeniia metriki [On the form of maintaning metrics]. Svedeniia Orenburhskoho Duchovnoho upravleniia [The data of the Religious Administration of Orenburg], 1916, no. 12–13. (In Tatar)
4. Salakhova E. Kollektsiia mahometanskich metricheskich knih v Natsionalnom archive Respubliki Tatarstan [The collection of Mohammedan registers of births in the National Archive of the Republic of Tatarstan]. *Otechestvennye archvy – Domestic Archives,* no 3, pp. 39–41. (In Russian)
5. Salakhova E.K. Metricheskie knigi kak istochnik izucheniya tatarskoy obshiny g. Astrakhani (vtoraya polovina XIX – nachalo XX vv.) [Parish registers as a source of studying the Tatar community of the city of Astrakhan (the second half of the 19th – early 20th centuries)]. *Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology*, 2016, vol. 1, no. 1, pp. 86–95. (In Russian)
6. Salakhova E.K. Metricheskie knigi kak istochnik po izucheniyu sotsalno-ekonomicheskoy zhezni i demograficheskoy kartiny tatarskikh dereven vtoroy poloviny XIX veka [Parish registers as a source of studying the socio-economic life and demographic profiles of the Tatar villages in the second half of the 19th century]. *VI Vserossiyskaya (XIV Mezhregionalnaya) konferentsiya istorikov-agrarnikov Srednego Povolzhya "Rossiyskaya derevnya: sotsialno-ekonomicheskaya istoriya i sovremennost"* [The 6th all-Russian (14th interregional) conference of historian-agrarians of the Middle Volga "Russian village: a socio-economic history and modernity"]. Ulyanovsk, 2016, pp. 300–307. (In Russian)
7. Salakhova E. Meticheskie knigi kak istochnik znaniy o tatarskom obshchestve XIX – nachala XX veka [Parish registers as a source of knowledge about the Tatar society of the 19th – early 20th centuries]. Tyurko-musulmanskiy mir: identichnost, nasledie I perspektivy izucheniya (К 80-letiyu professor M.A. Usmanova) [Turkic-Muslim world: Identity, heritage and prospects of studying. Dated to the 80th anniversary of Professor M.A. Usmanov]: collection of articles. Kazan, Kazan University Publ., 2015, pp. 294–299. (In Russian)
8. Salakhova E. Meticheskie metricheskie knigi Rossii [Muslim metric registers of Russia]. *Ekho vekov – The Echo of Centuries*, 2018, no 1, pp. 81–96. (In Russian)


**About the author:** Elmira K. Salakhova is a Candidate of Science (History), Senior Research Fellow, Department of History and Cultural Heritage of the Peoples of Tatarstan, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); ilsalah@mail.ru